# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 31 мартында
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында" 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9-10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3) план чорына дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) раслый;";

б) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

"$6^1$) дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми матбугат басмасы һәм Интернет челтәрендә рәсми сайт билгели;";

2) 4 статьяда:

а) 1 һәм 2 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан бер елдан алып өч елга кадәр срокка раслана.

Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планында (программасында) план чорына дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның төп юнәлешләре һәм бурычлары, әлеге мөлкәтне хосусыйлаштыруның икътисадтагы, шул исәптән икътисадның конкрет тармакларындагы, структур үзгәрешләргә йогынтысы фаразы,

хосусыйлаштырылырга тиешле дәүләт мөлкәтенең характеристикасы һәм аны хосусыйлаштыруның күз алдында тотыла торган сроклары күрсәтелә.

2. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) унитар предприятиеләрнең һәм ачык акционер җәмгыятьләрнең Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге акцияләренең, тиешле чорда хосусыйлаштырылуы планлаштырыла торган башка дәүләт мөлкәтенең исемлегеннән гыйбарәт.";

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

"$2^1$. Унитар предприятиеләрне үзгәртеп кору нәтиҗәсендә төзелгән ачык акционер җәмгыятьләрнең Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге акцияләрен ачык акционер җәмгыятьләрнең устав капиталларына кертем сыйфатында кертү, план чорына дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) үзгәрешләр кертмичә генә, билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән Татарстан Республикасы Президенты карарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә гамәлгә ашырыла.";

3) 6 статьяда "фаразлау планының (программасының) үтәлеше" сүзләрен "нәтиҗәләре" сүзенә алмаштырырга;

4) 8 статьядагы 2 өлешнең дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"мөлкәтнең башлангыч бәясе;";

5) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруны мәгълүмат белән тәэмин итү**

1. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы), дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар, күрсәтелгән мөлкәтне сату турында һәм аны сату йомгаклары хакында мәгълүмати хәбәрләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәсми матбугат басмаларында бастырып чыгарылырга һәм Интернет челтәрендәге рәсми сайтларда (алга таба – тиешенчә рәсми матбугат басмасы һәм Интернет челтәрендәге рәсми сайт) урнаштырылырга тиеш.

2. Хосусыйлаштыру турындагы федераль законнарда билгеләнгән белешмәләр мәгълүмати хәбәрдә һичшиксез бастырып чыгарылырга, шулай ук Интернет челтәрендәге рәсми сайтта, дәүләт мөлкәтен сатучының дәүләт мөлкәтен сату турында һәм дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру алыш-бирешләренең нәтиҗәләре турында Интернет челтәрендәге сайтында (алга таба – Интернет челтәрендәге сайтлар) урнаштырылырга тиеш.

3. Әгәр хосусыйлаштыру турында федераль законнарда бүтәне каралмаса, дәүләт мөлкәтен сату турындагы мәгълүмати хәбәр күрсәтелгән мөлкәтне сату көненә кадәр кимендә утыз көн кала рәсми матбугат басмасында бастырып чыгарылырга, шулай ук Интернет челтәрендәге сайтларда урнаштырылырга тиеш.

4. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру алыш-бирешләренең нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат әлеге алыш-бирешләр башкарылган көннән утыз көн эчендә рәсми матбугат басмасында бастырып чыгарылырга, Интернет челтәрендәге сайтларда урнаштырылырга тиеш.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 18 апреле
№ 9-ТРЗ